Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлегенең
Аппак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

24 ноябрь 2021 ел №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның 24 ноябрь 17 сәгать 30 минутта, узган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге "Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Аппак авыл җирлегенең Аппаково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: юлларны норматив хәлгә китерү, смета төзү өчен түләү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкен рәсмиләштерү?" соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 205 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 109 кеше, бу 53,2% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 103 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 6 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлегенең Аппак торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлегенең Аппак авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2022 елда 400 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: юлларны норматив хәлгә китерү, смета төзү өчен түләү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкен рәсмиләштерү?.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетысында бастырырга, Аппак, Мира урамы, д.71 территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче В.Н. Горбунова